Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № Х-6**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүматлар урнаштыру һәм бу мәгълүматларны гаммәви мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8, 8.1 маддәләре, «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт дазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-237 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүматлар урнаштыру һәм бу мәгълүматларны гаммәви мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның,

Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларының  керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүматлар урнаштыру һәм бу мәгълүматларны  гаммәви мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы XLI-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
X- номерлы карары белән
расланды

**Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүматлар урнаштыру һәм бу мәгълүматларны  гаммәви мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибе турында**

**Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә тарафыннан муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының  керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүматлар урнаштыру, шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән мәгълүматларны урнаштыру һәм

(яисә) аларны гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе билгеләнмәгән булса, әлеге мәгълүматларны урнаштыру өчен гомумроссия, республика һәм муниципаль гаммәви мәгълүмат чараларына (яисә) аларның гарызнамәләре белән бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен) мәгълүматлар бирү тәртибе билгеләнә.

2. Рәсми сайтта керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла һәм гаммәви мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшырыла:

а) муниципаль вазыйфаны биләүче затка (муниципаль хезмәткәргә), аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларга караган милек хокукындагы яисә алар файдалануындагы күчемсез милек объектларының исемлеге, мондый объектларның һәрберсенең төрен, мәйданын һәм урнашкан илен күрсәтеп;

б) муниципаль вазыйфаны биләүче затка (муниципаль хезмәткәргә), аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларга караган төр һәм марка күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) муниципаль хезмәткәр (муниципаль хезмәткәр), аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме.

г) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (туплау) капиталларында пайлар) сатып алу буенча килешүләр (килешү) башкарылган акча чыганаклары турында мәгълүматлар, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны биләгән затның (муниципаль хезмәткәр) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда кеременнән артып китсә.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны бастырып чыгару өчен бирелә торган мәгълүматларда түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) (әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш) муниципаль вазыйфаны биләүче затның (муниципаль хезмәткәр), аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, аталган затларның милек хокукында булган мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка мәгълүматлар;

б) муниципаль вазыйфаны биләүче затның (муниципаль хезмәткәрнең) хатынының (иренең) һәм балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының персональ мәгълүматлары;

в) муниципаль вазыйфаны биләүченең (муниципаль хезмәткәрнең), аның ире (хатыны), балалары һәм гаилә әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

г) муниципаль вазыйфаны биләүче затка (муниципаль хезмәткәргә), аның хатынына (иренә), балаларга, гаиләнең башка әгъзаларына яисә алар тарафыннан файдаланылучы күчемсез милек объектларының урнашкан урынын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

д) дәүләт серенә караган яки яшерен булган мәгълүмат.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында күрсәтелгән мәгълүматлар, биләгән муниципаль вазыйфа (муниципаль хезмәт вазыйфалары) тарафыннан биләү чорында аның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар урнаштыруга китергән барлык чорда, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнашкан һәм ел саен 14 эш көне дәвамында аларны бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң яңартыла.

5. Муниципаль вазыйфаны биләүче затлар (муниципаль хезмәткәрләр)тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны рәсми сайтта урнаштыру Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча (алга таба-Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәте) бүлекчәләре белән тәэмин ителә.

6. Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре:

а) массакүләм мәгълүмат чараларыннан гарызнамә кергән көннән алып өч эш көне эчендә аңа карата муниципаль вазыйфаны биләүче (муниципаль хезмәткәргә) затка хәбәр итәләр;

б) массакүләм мәгълүмат чарасыннан гарызнамә кергән көннән җиде эш көне эчендә аңа әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелүен тәэмин итә, сорала торган мәгълүматлар рәсми сайтта булмаган очракта.

7. Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче, әлеге Нигезләмә нигезендә мәгълүмат урнаштыруны һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирүне тәэмин итүче муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Нигезләмәне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә яисә конфиденциаль булган мәгълүматларны тараткан өчен җаваплылык тоталар.